ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

# ӘКИЯТЛӘР ИЛЕНДӘ

СЕРТОТМАС ҮРДӘК

КАЗ БЕЛӘН АККОШ

МАКТАНЧЫК ЧЫПЧЫК

КЕМ КӨЧЛЕ?

КУЯН КЫЗЫ

БАЛ КОРТЫ ҺӘМ ШӨПШӘ

БИКБАТЫР ҺӘМ БИККУРКАК



Абдулла Алиш әсәрләре буенча әкиятләр җыентыгы







УДК 821.512.145-343.4
ББК 83.84(2=632.3)-45
Ә 51

ISBN 978-5-906508-32-4

ТОИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

Абдулла Алиш әсәрләре буенча әкиятләр җыентыгы

# ӘКИЯТЛӘР ИЛЕНДӘ

Китап Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәме белән бастырылды.


| | |
|---|---|
| БАЛ КОРТЫ ҺӘМ ШӨПШӘ | 4 |
| КЕМ КӨЧЛЕ? | 12 |
| КАЗ БЕЛӘН АККОШ | 24 |
| МАКТАНЧЫК ЧЫПЧЫК | 36 |
| БИКБАТЫР ҺӘМ БИККУРКАК | 48 |
| СЕРТОТМАС ҮРДӘК | 60 |
| КУЯН КЫЗЫ | 80 |


**Махсус басма**

КАЗАН
2021

Монда татар
әкиятләре яши

tatbook.ru



# Бал корты һәм шөлшә



Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда төрле якка хәбәр дә салган:

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт хәзерләсә, ул савытта бал бер дә бозылмаса, әчемәсә, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәчәкмен, — дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр, бар да тырышып савыт эшләгәннәр.







Күп тә үтмәгән, бөҗәкләр төрле яктан очып килгәннәр. Бар да үзләре эшләгән савытларны Чәчәкләр башлыгына китергәннәр.

— Менә дигән савыт, балны кара салып, — дигәннәр. Чәчәкләр башлыгы барысын да борып җибәргән:

— Ашыккансыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми, — дигән.



Шөпшә белән Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр, беренчелекне алырга өмет иткәннәр. Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән: еракерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала, аны алып кайтып, үзе хәзерләгән матур күзәнәкләрне тикшереп карый икән.



Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли икән дә, кояш кыздыра башлагач, оясына кереп йоклый икән.

Ярыш көне килеп җиткән. Бал корты белән Шөпшә Чәчәкләр башлыгы янына очып килгәннәр.

Чәчәкләр башлыгы савытларга бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган, ә Бал кортының кәрәзеннән акмаган.



— Тырышканнар, күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм, — дигән Чәчәкләр башлыгы.



Шул көннән башлап, бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар, ә шөпшәләр ялкаулыклары аркасында хурлыкка калганнар.



# КЕМ КӨЧЛЕ?




Кышын да үзенең яшеллеген җуймый торган нарат агачы астында бүген бәйрәм — Сабан туе. Зур мәйдан тирәли кунаклар тезелешеп утырганнар. Һәммәсе дә үзенең һөнәрен, осталыгын, кыюлыгын күрсәтергә ашыга. Күбәләк-түгәрәк, канатларын җилпеп, оста җыры, матур биюләре белән кунакларның күңелләрен тапмакчы була.

Чикерткә капчык киеп йөгерүдә барчасын шаккатырырга тырыша. Үрмәкүч тә үрмәләп килеп җиткән: биек баганага менүдә аңа тиңнәр юк. Кырмыскалар капчык белән сугыша, Әкәм-төкәм узыша... Һәммәсе дә бик матур гына бәйрәм итә.



Сабантуй бәйрәме кызганнан-кыза барды һәм һәрвакыттагыча бәйрәмнең иң югары ноктасы — көрәш башланды. Нәкъ менә көрәш келәмендә кемнең иң көчле икәне ачыкланачак.



Беренчеләрдән булып киләмгә Кара еланга каршы кырмыскалар чакырылды. Үлән арасыннан мыштым гына, берәүгә дә сиздерми, тын гына үрмәли торган Кара елан үрле-кырлы сикерде. Зәһәрле телен чыгарып, агуын чәчеп карады, кырмыскаларны чагарга уйлады. Кырмыскалар Еланны аның саен катырак тешләделәр. Кунаклар бар да, таңга калып, шул хәлне күзәтеп тордылар. Кырмыскаларның батырлыкларын мактадылар.





Батыр кырмыскалар Еланны җиңеп чыккач, кунаклар көрәшнең дәвам итүен көттеләр, урманның саф һавасында, агач ышыгында тагы бераз күңел ачмакчы булдылар.





Икенче көрәш башланды. Чикерткә Суалчанга каршы! Чикерткә-микерткә җиләк яфрагына менеп утырды, озын аякларын җайларга тотынды. Бөтен кунаклар аңа карадылар: «Нишли инде бу?» — дип көтеп тордылар. Ул озын аяклары белән бер кечкенә яфракны этте, очкыч шикелле очып та китте. Кунаклар аның һөнәрен мактадылар, шулкадәрле ерак сикерә алуына таң калдылар. Күп тә үтмәде, икенче кунак кузгалды: Суалчан-оялчан боргаланды да сыргаланды, Чикерткәне җир астына алып кереп китәргә маташты. Шулай итеп Суалчан-оялчан үз максатына иреште һәм Чикерткә-микерткәне җиңде.







Өченче көрәш башланды: Күбәләк-түгәрәк Яфрак көясенә каршы чыкты. Бу көндәшләрне туганнар дияргә дә буладыр, мөгаен. Башта Күбәләк-түгәрәк үзе дә көя булган, яфрак ашап симереп, «курчак»ка әйләнгән, аннан гына шушы төскә кергән. Күбәләк-түгәрәк чәчәк урындыгыннан кузгалды. Пыр-пыр итте дә агач башыннан очып килеп җитте. Яфрак көясе елмаеп кына Күбәләкне күзәтә башлады. Кунакларның Күбәләк-түгәрәк яклы булулары сизелеп торды. Озак көрәшергә туры килмәде, канатлары ярдәмендә Күбәләк-түгәрәк җиңеп чыкты.



Тукранбаш чәчәгендә нидер тавышланды. Кунаклар шунда борылдылар һәм чәчәктән бал суырып ятучы Бал кортын күрделәр. Ул кунакларның аңа таба борылуларын гына көтте, шунда ук көндәше Шөпшәгә ташланды. Тик көчләр тигез булып чыкты.

Гасыр көрәше якынлашты: Чебенгә каршы Үрмәкүч чыкты.







Ерак та түгел корыган яфраклар кыштырдады, чыбык-чабыклар шартлады, җирне тетрәтеп, кемдер атлады.

Кайсыдыр бөҗәк:

— Кеше килә! — дип кычкырды. Кунаклар сафында буталыш башланды: Чикерткә бер читкә сикерде, Суалчан җиргә сеңде, Бал корты чәчәккә яшеренде, Күбәләк һавага күтәрелде, Яфрак көясе яфракка сыенды, Чебеннең коты очты, кая да кузгала алмады.





Урмандагы барлык агачларның, андагы усал ерткычларның хуҗасы — кеше атлады.

Шулай итеп, Чебен белән Үрмәкүч көрәшә алмый калдылар. Алар качучы кунаклар белән бергә кузгалдылар. Эх, әрәм калды бит, әрәм калды. «Кем көчле?» дигән бәхәс бетмичә калды. Сез, бәлкем, аны үзегез белерсез, кем көчле икәнен әйтеп бирерсез?

# Каз белән Аккош





Очы-кырые күренмәгән болын уртасында зур бер күл булган. Тирәләре аның яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган булган.

Шул тыныч күлдә Аккош белән Каз яшәгәннәр. Балык ашаганнар, су эчкәннәр, йомырка салганнар, бала чыгарганнар.



Җәйнең матур бер көнендә бу ике күрше үзләренең балалары турында сөйләшкәннәр.

Каз әйткән:

— Белмим, нишләргә инде... Улым беркая бармый, юньле ризык ашамый, көннәр буе өйдә утыра, компьютер уеннарына кереп киткән, — дигән.

Аккош әйткән:

— Минем балам бик яхшы ашый, зур үсә, — дигән.



Дуга муен — Аккош бәбкәсе кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат-кат чәйни, тәмле итеп ашый икән. Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.



Каз үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап караган: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыслалар тотып китерә икән. Баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән.



Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга-эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән. Урамга да чыкмый икән – тик өйдә генә утыра.



Көннәрдән бер көнне нәни Аккош, Каз бәбкәсе өенә кереп, компьютерда уйнап карарга булган. Компьютердагы велосипедта ярышу уены балаларда чын велосипедта йөрү теләген тудырган.



Алар әниләренә килгәннәр дә:

— Әни, безгә велосипед алыйкчы! — дип үтенгәннәр.

— Ярый, барсак — барыйк, алсак — алыйк, — дигәннәр әниләре.




Улларын иярткәннәр дә велосипед сатыла торган кибеткә киткәннәр. Анда барып кергәннәр дә әниләре:

— Иптәшләр, безнең сөекле улларыбызга велосипед бирсәгезче! — дигәннәр.



Шунда Аккошның улына:

— Теләгәнеңне сайлап ал, акыллым! — дип, көмеш төсле ялтырап торган велосипедлар китереп биргәннәр. Аккош бәбкәсе велосипедка менеп атланган һәм йөгерткән дә киткән. Аккош, үз баласының булдыклылыгын күреп, елмаеп, кәефләнеп карап тора икән, ә Аккош бәбкәсе велосипедны йөгертә дә йөгертә икән.



Каз бәбкәсенә дә чират җиткән. Ул, Аккош бәбкәсе белән бер яшьтә булса да, аңа караганда бик ябык, буйга да бик кечкенә икән. Аңа да велосипедның көмеш төслесен биргәннәр.

Каз бәбкәсе атланып караган — булдыра алмаган. Әйләндермәгәч, велосипед та китмәгән. Кибеттә эшләүче абыйлар Каз бәбкәсенә:



— Каз бәбкәсе беркайчан да велосипедта йөри алмаячак, чөнки ул бик хәлсез, — дип әйткәннәр.



Каз бәбкәсе бик күңелсезләнеп кайтып киткән, ә Аккош бәбкәсе аңа ярдәм итәргә булган.

Хәзер инде, велосипедка аягым җитсен дип, Каз бәбкәсе һәр көнне Аккош бәбкәсе белән бергә иртәнге күнегүләр ясый, азыкны да күп ашый, вакытында йоклый да, саф һавада да уйный икән.





Күп тә үтми, Каз бәбкәсе буйга үсеп, чыныгып китә. Хәзер инде аның өчен велосипедта ярышу компьютер уеннарыннан күпкә кызыклырак икән.

# Мактанчык чыпчык



Тәрәзәгә каршы бер озын колга сузылган. Ул колгага нарат такталардан эшләнгән оя куелган. Әле кичә генә балалар ул ояны ашыга-ашыга эшләп бетерделәр, ә бүген инде анда яз кунаклары — сыерчыклар килделәр. Ояның эчен-тышын җентекләп карадылар, бик ошаттылар. Аны ясаучыларга рәхмәт укыдылар, матур итеп сайрап куйдылар.

Сыерчык оясына каршы тәрәзә башында бер карт Чыпчык утыра. Ничә еллардан бирле инде ул шунда тора. Салам-солымнарны, йон-мамыкларны җыеп, оя ясаган. Салкыннар килгәч тә җылы якларга очмаган, шул ояда кышлаган ул Чыпчык.

Яңа кунакларны Чыпчык нишләптер кәефсез каршы алды.

— Күңелсез иде, күршеләр булды, — дип эченнән бераз шатланды.



Ә үзе:

— Сайраулары белән колакны тондырып бетерерләр, рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмәсләр, туктагыз дисәң дә, туктамаслар, күрше димәсләр, — дип уйланды.

Чыннан да, шулай булып чыкты. Сыерчыклар монда Чыпчык абзый яши дип тормадылар, көне буе өзелеп-өзелеп сайрадылар.

Чыпчыкның моңа бик ачуы килде, ямьсез тавыш белән күршеләренә җикеренде:

— Бөтен тынычлыгымны боздыгыз, сайраган булып, колагымны тондырдыгыз. Ичмасам, чыпчыклар төсле сайрый алсагыз икән, алардан да уздырсагыз икән... Безнең җырны бар тавыклар хәйран калып тыңлый, безне хуҗа да бик зурлый...



Сыерчыклар, мактанчыкның бу сүзләрен ишетеп, аптырап калдылар. «Бу әллә юләрме икән?» — дип уйлап алдылар.

Җае чыккан саен, Чыпчык мактана бирде. Әй мактады чыпчыкларны — күкләргә чөерде. Имештер, дөньяда алардан батыррак бар микән, имештер, аларның өйләрен берәү дә җимерә алачак түгел. Көчле давыл гына булсын, имеш, сыерчыклар оясы беркетелгән колга сыначак, оя йөзтүбән капланачак.



— Күрербез әле ничек булганын, кем отылганын, — дип җавап бирделәр сыерчыклар.

Беркөнне Чыпчык үз өенә атылган уктай кайтып керде. Аның артыннан күктә, биектә Карчыга күренде.

Батыр Чыпчыкның кемнән куркуын сыерчыклар бик яхшы белделәр.



— Батырның тавышы-тыны юк, өенә бикләнде, ахры, — дип көлделәр.

Бераз яткач, Чыпчык оясыннан башын чыгарды, күршеләренә сүз салды:



— Күрдегезме Карчыга белән минем ничек сугышканны? Әй бирдем дә соң үзенә, утлар күренгәндер күзенә! — дип сөйләнде.

Сыерчыклар бер сүз әйтмәделәр, мактанчыкның кәефен җибәрмәделәр.



Берзаман Чыпчык һәрвакыттагыча мактанып тора иде:

— Хуҗа Песиенең күзен чукыдым, әй кирәген бирдем...

Сыерчыклар аның сүзен тыңлагандай иттеләр, ләкин соңыннан әйттеләр:

— Ул Песине әле бая гына күрдек, күзләре дә бик исән, мыраулап йөридер иде, — диделәр.



— Юк, юк, күршеләрнекен күргәнсездер, ә безнең хуҗаныкы инде сукыр, безгә һөҗүм итәргә куркыр, — диде Чыпчык.



Ә шулчак әлеге Песи, посып кына, өй кыегы буйлап тәрәзә башына таба үрмәләде. Мактанчык Чыпчык, арты белән торганга, аны күрмәде. Мәче инде Чыпчыкка якынлашты. Сикереп, тегене эләктереп алмакчы иде, шулчак сыерчыклар очып килеп җиттеләр. Песинең күзен чукып җибәрделәр, аны кире чигендерделәр. Песи өй кыегыннан чормага сызды.



Мактанчык Чыпчык куркуыннан калтырап төште, сүз дә әйтә алмады.

Кинәт ул телгә килде һәм болай диде:

— Ярый, бәхете бар икән, китеп котылды, күрмәгәнен күргән булыр иде!



Сыерчыклар тагын көлделәр һәм аңа болай диделәр:

— Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә!



# Бикбатыр белән Биккуркак



Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, кишер кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.

Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа бала «Бикбатыр» дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрли, шуңа ул аны «Биккуркак» дип атаган.



Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән.



Куркуыннан куян нишләргә дә белмәгән, ярдәм сорап кычкыра башлаган. Шул вакыт песи килеп җиткән.



— Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан үлгән булыр идем, — дигән куян.





— Әй юләр, юләр, үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич, — дип, Биккуркактан көлгән Бикбатыр.



Бервакытны куян куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп типкән, чөнки нәрсәдер бик нык итеп кыштырдый икән. «Хәзер идән астыннан чыга да кыштырдаучы нәрсә мине кабып йота», — дип уйлый икән куян.

Песи дә колакларын торгызган. «Ул да курка, ахры», — дип уйлаган куян. Шулчак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян һушсыз була язган. Караса, песи авызына нәрсәдер капкан.





Ул куян янына килгән дә:

— Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде, — дип, бер кечкенә генә кара әйберне куянга күрсәткән.

— Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы? — дигән куян, гаҗәпләнеп.





Бервакыт ишектән эт килеп кергән дә каты итеп өрергә керешкән. Куркуыннан куян караватастына качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан һәм, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан. Эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган ул. Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.

Ә Бикбатыр, үзенең батырлыгы аркасында, бу бәладән дә бик оста котылган.





# Сертотмас үрдәк



Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер Үрдәк булган. Ул үзе, сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, йә бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим», — дип башлап китә торган булган ул сүзен.





Көннәрдән бер көнне йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән.

«Нигә белдермәскә кушты икән?» — дип, Үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.



Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу», — дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!» — дигәннәр алар Үрдәккә.



«Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» — дигәннәр. Үрдәк күнгән: «Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде», — дигән.

Иртә торгач та, Үрдәк уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча, бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре-тәпиләре үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән...

Бара-бара, куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.



Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер Керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан:

— Кая барасың болай? — дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:



— Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр, — дигән.

— Синең өең еракмы соң? — дигән Керпе. — Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.





— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! — дигән Үрдәк. Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр, — дигән. Керпенең бу акыллы киңәшенә Үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.



Бара-бара, Үрдәккә озын колаклы бер Куян очраган, һәм ул да аңардан сораган:

— Әй, бүрекле Үрдәк, көзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?



— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды, — дигән Үрдәк, Керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. Куян эченнән генә: «Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән», — дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк, — дигән дә Куян һәм куаклык эченә кереп югалган.



Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара, бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры Аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән Куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында Аюдан сораган:

— Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?



Аю:

— Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган. — Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың, — дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән», — дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.



Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иткән. Аның саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына Бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:



— Әй, бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына, курыкмыйча, батырланып ничек йөрисең? — дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен Бүрегә дә әйткән. Усал Бүре тешләрен шыгырдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән», — дигән, ә Үрдәккә: «Андый кешене күргәнем юк!» — дигән дә үзе куаклар арасына кереп югалган.





Үрдәк һаман туктамаган. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәкләрдән дә бу турыда сорашып бара икән.

Бара-бара, аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер Төлке килеп чыккан:

— Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме? Янында эте, кулында балтасы бар иде, — дигән.

— Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны! — дигән Төлке. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар.



— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите, — дип әйтүгә, Үрдәк чыгып качкан.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам, — дигән Төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.

Ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән. Төлке, хәйләкәр булса да, сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр, Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.





# Куян кызы



Бер соры Куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.

Көннәрдән бер көнне Куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.



— Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, — дигән.

Кызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул, яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин Куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнисе тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе, аларны эзләп табып, баласына кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә, ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул тагын салып ташлаган.

Кар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде аксый-аксый әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта! — дигән.

Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

— Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, — дигән.

«Инде ни эшләргә?» — дип уйга баткан Куян. «Бу баланы кая алып барырга, ничек дәваларга?» — дип кайгырган.





Шул вакыт нәрсәдер кычкырган. Куян агач башына күтәрелеп караган икән — Тиенне күргән. Ул Куянга болай дигән:

— Кайгырма, туганкай, йомшак Куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен доктор Айболитка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк.



Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, доктор Айболитның өенә үзе илтергә булган.

Куян кызын күтәргән дә доктор Айболитка киткән. Тиен, агачтан агачка сикереп, аңа юл өйрәткән.



Барып җитсәләр, доктор Айболитның эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр икән. «Балаларны чиратсыз карыйм мин», — дигән доктор Айболит. Куян кызын доктор бүлмәсенә алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. Доктор Айболит Куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм аңа болай дигән:

— Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма.



Доктор Айболитка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып, өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, Куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.



Абдулла Алиш әсәрләре буенча әкиятләр җыентыгы

# ӘКИЯТЛӘР ИЛЕНДӘ

Книга издана при поддержке Комиссии при Президенте
Республики Татарстан по вопросам сохранения и развития татарского языка
и Министерства культуры Республики Татарстан

Главный редактор **Марат Ганиев**
Главный режиссёр **Сергей Киатров**
Литературные редакторы **Анна Белоброва,**
**Алсу Низамеева, Фарида Ахметзянова, Зухра Фасхиева**
Художественный редактор **Дамир Бариев**
Художники **Гузель Гилазетдинова,**
**Жанна Буланкова, Дарья Митрофанова,**
**Эльвира Шевцова, Аида Ромашова, Ольга Волкова,**
**Александра Ахтямзанова, Эльвина Шакирова**
Верстальщик **Минзиля Кадырова**
Технический директор **Ильдар Низаметдинов**
Руководитель проекта **Азат Ганиев**

Подписано в печать 06.07.2021
Печать офсетная. Тираж 5000. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
Татарским детским издательством материалов в типографии филиала
АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© Татарское Детское Издательство
**www.tdpress.ru**

ТДИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ





ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

ТОИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАПАР НӘШРИЯТЫ
www.tatbook.ru

## Абдулла Алиш әсәрләре буенча әкиятләр җыентыгы

www.варислар.рф

«Татарстан Варислары» сериясенең электрон китаплары **www.варислар.рф** порталында урнаштырылган. Анда әлеге китапларны һәм аларга бәйле мультфильмнарны һәм мультимедиаларны йөкләтеп алу һәм карау мөмкинлеге дә бар.

Электронные книги серии «Татарстан Варислары» размещены на портале **www.варислар.рф** с возможностью скачивания и просмотра книг и соответствующих мультфильмов и мультимедиа.

© Татарское Детское Издательство
www.tdpress.ru

ISBN 978-5-906508-32-4
9 785906 508324